**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 декабрь № 921

г. Казань

Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татар телен саклау, Россия Федерациясендә татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, әлеге өлкәдә гражданнарның инициативаларына ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантларны гамәлгә куярга.
2. Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\921.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 декабрь, 921 нче карары белән расланды

**Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү тәртибен билгели.

1.2. Грантлар бирү максаты – татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау, үстерү һәм куллану өчен шартлар тудыру.

1.3. Грантлар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) чараларын тормышка ашыруга тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Дәүләт программасы нигезендә әлеге максатларга бүлеп бирелә торган акча чикләрендә биш грантның күләме 100 000 (йөзәр мең) сум тәшкил итә.

1.5. Конкурс комиссиясе грантка дәгъва кылучыларның проектларын (программаларын), заявкаларын һәм конкурс материалларын карап тикшерә һәм «Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклаган һәм үстергән өчен» номинациясендә грантлар бирү турында карар кабул итә.

1.6. Грант алучылар конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

## II. Төп төшенчәләр

2.1. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

Грантлар – субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы – Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан Грантлар бирү вәкаләтләре йөкләнгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы;

Конкурс – Грантлар бирү өчен галимнәрне, мәгариф оешмаларын һәм иҗтимагый оешмаларны сайлап алуга бәйле чара;

Конкурста катнашучылар – татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау, үстерү һәм аның кулланылыш даирәсен киңәйтү өлкәсендә проектлар (программалар) тормышка ашыра торган галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар;

комиссия – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 февраль, б-389 нчы боерыгы нигезендә төзелгән Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем;

грант алучылар – Конкурста җиңүчеләр дип танылган, Вәкаләтле орган белән Грантлар алуга килешү төзегән галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар;

галим – «фәннәр кандидаты» һәм (яки) «фәннәр докторы» гыйльми дәрәҗәсе бирелгән мәгариф оешмасы яки фәнни оешма хезмәткәре.

## III. Төп максатлар

3.1. Грантлар бирүнең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру;

гражданнар җәмгыяте институтларын үстерүдә галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның ролен арттыру;

галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның иҗтимагый әһәмияттәге проектларны (программаларны) тормышка ашыруда катнашуын активлаштыру;

татар телен Татарстан Республикасыннан читтә үстерү һәм аның кулланылыш даирәсен киңәйтү өчен шартлар тудыру.

## IV. Конкурста катнашу хокукы

4.1. Конкурста катнашуга законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшчәнлекләрен Конкурс игълан иткән көнгә кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасыннан читтә гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары, иҗтимагый оешмалар, шулай ук Россия Федерациясе субъектларындагы, Татарстан Республикасыннан тыш, мәгариф оешмалары яки фәнни оешмалар галимнәре кертелә.

4.2. Мәгариф оешмалары, иҗтимагый оешмалар һәм галимнәр Конкурска күп дигәндә бер проект (программа) кертә.

4.3. Мәгариф оешмалары, иҗтимагый оешмалар һәм галимнәр конкурс нигезендә сайлап алуда 2 елга 1 тапкыр катнашырга хокуклы.

## V. Конкурсны үткәрү тәртибе

5.1. Конкурсны үткәрү шартлары һәм вакытлары турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми

сайтында (алга таба – Сайт) комиссия Конкурс үткәрү хакында карар кабул иткән көннән соң өч көн эчендә урнаштырыла.

5.2. Конкурста катнашу өчен галимнәр түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча заявка;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча проектның (программаның) тасвирламасы;

финанслашу турында гарантия хаты;

тапшырыла торган документлар исемлеге.

Мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча заявка;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча проектның (программаның) тасвирламасы;

җитәкче мөһере (Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда) һәм имзасы белән расланган уставның күчермәсе;

финанслашу турында гарантия хаты;

тапшырыла торган документлар исемлеге.

Грантлар бирү шарты булып югары белем бирә торган мәгариф оешмасы галимнәренең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның проектны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми суммасыннан кимендә 20 процент күләмендә бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән проектны финанслау буенча йөкләмәләре тора.

5.3. Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар беркетелгән, бит саннары куелган һәм югары белем бирә торган мәгариф оешмасының, мәгариф оешмасының һәм иҗтимагый оешманың вәкаләтле заты мөһере һәм имзасы белән расланган булырга тиеш. Барлык документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Югары белем бирә торган мәгариф оешмасының, мәгариф оешмасының һәм иҗтимагый оешманың вәкаләтле заты мөһере һәм имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш, төзәтмәләр рөхсәт ителми.

5.4. Документлар кәгазьдә һәм электрон чыганакта тапшырыла яки 420111, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт; e-mail: mon@tatar.ru адресы буенча җибәрелә.

5.5. Документларны кабул итү Сайтта Конкурс үткәрү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

5.6. Әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм теркәү алар кертелгән көнне Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.7. Конкурста катнашуга заявка кабул иткәндә Вәкаләтле орган аны кертелгән көнне Конкурста катнашуга зявкаларны исәпкә алу журналында терки һәм Конкурста катнашучыга, аны алган көнне һәм бирелгән теркәү санын күрсәтеп, заявка алу турында раслама бирә.

Заявка Вәкаләтле органга почта аша җибәрелгәндә, ул бер көн эчендә заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлә. Бу очракта заявка алу турында

раслама төзелми, заявкаларны исәпкә алу журналында теркәү көне буларак почта бүлегендә штемпель белән расланган почта аша җибәрелгән әйберне элемтә оешмасына тапшырган көн күрсәтелә.

5.8. Әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән документлар аларны тапшыру вакыты тәмамланган көннән соң өч көн эчендә комиссия тарафыннан карап тикшерелә.

5.9. Конкурста катнашуга әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар кертелә.

5.10. Галимнәргә, мәгариф оешмасына һәм иҗтимагый оешмага Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмдә тапшырмау;

б) документларның әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

в) документларны Конкурска тапшыру вакыты тәмамланганнан соң тапшыру;

г) әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булуы ачыклану;

д) әлеге Нигезләмәнең 4.1, 4.3 нче пунктларында билгеләнгән таләпләрне бозу.

5.11. Конкурста катнашуга кертелгән галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар исемлеге һәм Конкурста катнашуга кертелмәгән галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар исемлеге комиссия утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

5.12. Комиссия утырышы беркетмәсен раслаганнан соң Конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук Конкурста катнашуга кертелмәгән галимнәр, мәгариф оешмалары һәм иҗтимагый оешмалар исемлеге эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Сайтта урнаштырыла.

5.13. Конкурста катнашуга кертелмәгән галимнәргә, мәгариф оешмаларына һәм иҗтимагый оешмаларга хәбәр итү беркетмәне раслаган көннән соң өч көн эчендә комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан хәбәрнамә җибәрү юлы белән өстәмә рәвештә гамәлгә ашырыла.

5.14. Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча билгеләнә.

5.15. Конкурста катнашучыларның заявкалары комиссия утырышын үткәргәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә комиссия әгъзаларына карап тикшерү өчен җибәрелә. Комиссия әгъзалары аларга заявкаларны биргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны, аларга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм бәяләү кәгазьләрен Вәкаләтле органга бирә.

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү йомгаклары буенча өч көн эчендә рейтинг төзелә.

5.16. Конкурста җиңүчеләрне сайлап алу процедурасы комиссия утырышында

рейтинг нәтиҗәләре буенча комиссия әгъзалары тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнаша, хокуклы санала. Комиссия карарлары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының гади тавышлар күпчелеге нигезендә кабул ителә. Комиссия утырышы ел саен агымдагы елның 30 ноябренә кадәр үткәрелә.

5.17. Комиссия утырыш барышында Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый һәм Грантлар бирү турында карар кабул итү өчен Вәкаләтле органга рекомендацияләр бирә.

5.18. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, комиссия рәисе яисә утырышта рәислек итүче һәм рәис булмаган вакытта аның вәкаләтләрен башкаручы урынбасары һәм комиссиянең җаваплы секретаре тарафынна имзалана.

5.19. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат Конкурста җиңүчеләр исемлеген раслаган көннән соң өч көн эчендә Сайтта урнаштырыла.

## VI. Грантлар бирү тәртибе

6.1. Грантлар агымдагы елның 10 декабренә кадәр әлеге Нигезләмәнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән проектны тормышка ашыру өчен бирелә.

6.2. Вәкаләтле органның Грантлар бирү турындагы карары Вәкаләтле орган һәм Конкурста җиңүче – грант алучы арасында килешү (алга таба – Килешү) төзү өчен нигез булып тора.

6.3. Килешү Сайтта Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң 10 көн эчендә төзелә.

6.4. Килешү формасын Вәкаләтле орган раслый.

6.5. Килешүдә Грантның күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган Грантны грант алучы тарафыннан агымдагы елда кайтару очраклары, Гранттан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе, Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант алучының грантны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә грант алучының ризалыгы күздә тотыла.

6.6. Вәкаләтле орган Грантны Килешү төзегәнннән соң җиде көн эчендә грант алучының хисап счетына күчерә.

6.7. Грант алучы Вәкаләтле органга Гранттан файдалану турында хисапны Вәкаләтле орган раслаган форма буенча һәм Килешүдә күздә тотылган тәртиптә тапшыра.

## VII. Грант алучының җаваплылыгы

7.1. Грант алучы Вәкаләтле органга тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

7.2. Грант түбәндәге очракларда грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш:

а) грант алучының Грант бирү шартларын үтәмәве;

б) Гранттан максатка ярашсыз файдалану.

7.3. Килешүдә күздә тотылган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган Грант хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

7.4. Грант алучы Грантны кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 7.2 һәм 7.3 нче пунктларында билгеләнгән вакытлар чыккан көннән соң җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

7.5. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Грантны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен грант алучы тарафыннан үтәүне законнар нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

7.6. Гранттан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту законнар нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

**Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар алуга конкурста катнашу өчен заявка**

1. Гариза бирүче турында мәгълүматлар:

***Юридик затлар өчен***

Гариза бирүче оешманың исеме һәм адресы, ИНН:

______________________________________________________________________

Адрес: _______________________________________________________________

(индекс) (юридик адрес) (факттагы адрес)

______________________________________________________________________

(телефон) (факс) (E-mail)

Оешма җитәкчесе:

Ф.И.Ат.ис.:____________________________________________________________

Тел.: _________________________________________________________________

Адрес:________________________________________________________________

E-mail: _______________________________________________________________

***Физик затлар өчен***

Ф.И.Ат.ис.:____________________________________________________________

Вазыйфасы һәм эш урыны:_____________________________________________

Тел.: _________________________________________________________________

Адрес: ________________________________________________________________

E-mail: _______________________________________________________________

2. Проект (программа) турында мәгълүмат:

Исеме:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Юнәлеше:_____________________________________________________________

Авторы:_______________________________________________________________

Элемтә өчен мәгълүмат:_______________________________________________

3. Сезнең кайчан да булса дәүләт гранты яки муниципаль грант алганыгыз булдымы? Әгәр булса, елын, проектның исемен һәм грантның суммасын күрсәтегез:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

4. Проектның (программаның) кыскача тасвирламасы (проектның төп бүлекләре эчтәлеген кыскача бәян итү):
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

5. Түләү реквизитлары:

Банкның исеме: _______________________________________________________

Адресы:_______________________________________________________________

хисап счеты (р/с)______________________________________________________

Әлеге заявкада китерелгән бөтен мәгълүматның, шулай ук өстәмә материалларның төгәл һәм дөрес булуын белдерәм һәм вәкаләтле органның миннән һәм дәүләт хакимияте вә муниципаль хакимият органнарыннан китерелгән белешмәләрне тәгаенли торган мәгълүмат соратып алу хокукын раслыйм.

Ф.И.Ат.ис. ______________________________/ ______________/
(имза)

М.У.[1]

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

Ф.И.Ат.ис. ______________________________/ ______________/
(имза)

Дата:

_________________________

[1]Юридик затлар өчен (законнарда билгеләнгән очракларда).

Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

**Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар алуга конкурста катнашу өчен проект (программа) тасвирламасы**

(5 биттән артык түгел)

1. Проектны (программаны) тормышка ашыра башлаганда хәлнең гомуми тасвирламасы (1 биттән артык түгел):

______________________________________________________________

______________________________________________________________

2. Проектның (программаның) максатлары һәм бурычлары:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

3. Чаралар планы (төп чаралар тасвирламасы, проектны (программаны) тормышка ашыру этаплары һәм вакытлары):

| Т/с | Тормышка ашыру этабы | Чараның исеме | Тормышка ашыру вакытлары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектның (программаның) кирәкле булуын нигезләү:

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

5. Проект (программа) бюджеты (күздә тотылган керемнәр һәм планлаштырылган чыгымнар сметасы, аны нигезләү):

Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):
Грант күләме (сум):_______________________________________________
Күздә тотылган финанслашу суммасы: _________________________________

(сум)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз акчалары | Таләп ителә торган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| Барлыгы | | | | |

6. Проектны (программаны) тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәләре:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар CD, DVD-мәгълүмат саклау җайланмаларында, электрон рәвештә һәм бастырып чыгарылып (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) кертелә.

Ф.И.Ат.ис. ______________________________/ ______________/
(имза)

М.У.[1]

Дата:

________________________________

[1] Юридик затлар өчен (законнарда билгеләнгән очракларда).

Татар телен Татарстан Республикасыннан читтә саклау һәм үстерү буенча галимнәрнең, мәгариф оешмаларының һәм иҗтимагый оешмаларның инициативаларына ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары**

| Т/с | Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары | Бәяләмә (балларда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Икътисадый нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 1.1. | Проектны (программаны) тормышка ашыру өчен планлаштырылган чыгымнар һәм аның көтелә торган нәтиҗәләре чагыштырмасы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |
| 1.2. | Проектны (программаны) тормышка ашыруга чыгымнарның нигезләнгән булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |
| 1.3. | Проектны (программаны) тормышка ашыруга бюджеттан тыш чыганаклардан күздә тотылган керемнәр күләме, акча, башка мөлкәтне, мөлкәт хокукларын, түләүсез башкарыла торган эшләр һәм күрсәтелә торган хезмәтләрне, үз ирекләре белән эшләүчеләр хезмәтен кертеп (проектны (программаны) тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми суммасыннан кимендә 20 процент) | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2. | Социаль нәтиҗәлелек критерийлары | |
| 2.1. | Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проект (программа) бурычларына туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |
| 2.2. | Планлаштырылган чараларның проектны (программаны) тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |
| 3. | Өстәмә критерийлар | |
| 3.1. | Иҗтимагый оешманың, мәгариф оешмасының проектны (программаны) тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы һәм биналары булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |
| 3.2. | Иҗтимагый оешманың һәм мәгариф оешмасының проектны (программаны) тормышка ашыру өчен кирәкле кадрлар ресурслары булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0дән башлап 10га кадәр |

Ф.И.Ат.ис. ________________________________/ _______________/
(имза)

М.У.[1]

Дата:

________________________________

[1] Юридик затлар өчен (законнарда билгеләнгән очракларда).